**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 18 июне** **№ 35**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советының «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләренең коррупциячел хокук бозуларны кылган өчен җаваплылыгы турында» 2012 елның 13 декабрендәге 63 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Кама Тамагы районы прокуратурасының 2021 елның 19 маендагы 02-08-02-21 номерлы протесты һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына үзгәреш кертү турында» 2013 елның 17 июлендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Советы карар чыгарды:

1. “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге Советының 2012 елның 13 ноябрендәге 63 номерлы карары белән расланган коррупцион хокук бозулар кылган өчен “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турындагы нигезләмәгә, преамбулда “Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында” 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы” сүзләрен “Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы” сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы ш.т.п., Совет ур., 11нче йорт (административ бина);

- ТР, Кама Тамагы районы, Кама Тамагы ш.т.п., К. Маркс, 105 йорт (китапханә бинасы),

шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кама Тамагы шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге башлыгы урынбасары Дәүләтшин Раил Хәмит улына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы «Кама Тамагы
шәһәр тибындагы поселогы»
муниципаль берәмлеге Башлыгы - Совет рәисе Н. А.Вазыйхов